**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«10» 03 2020 ел Яр Чаллы ш. № 710

Районда хәрби хезмәткә чакырылучылар
көнен үткәрү турында

Муниципаль район Башкарма комитетының 2019 елның 10 январендагы 3 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Тукай муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү район комплекслы программасы»н гамәлгә ашыру максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Районда «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен» «Татарстан» совхозы мәдәният йорты базасында 2020 елның 15 апрелендә 18.00 сәгатьтә үткәрергә.
2. Финанс чыгымнарын «Тукай муниципаль районы яшүсмерләр клубы» МБУ средстволары хисабына кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Тукай районы хәрби комиссарына 2020 елның язында РФ Хәрби Көчләренә чакырылырга тиешле гражданнарга хәбәр итүне тәкъдим итәргә.
4. Авыл җирлекләре Башлыкларына 2020 елның язында РФ Хәрби Көчләренә чакырылырга тиешле гражданнарны «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне» чарасын үткәрү урынына алып килүне оештырырга тәкъдим итәргә.
5. Чараны үткәрү өчен җаваплы итеп район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгын һәм район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгын билгеләргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л. Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның ___ 10.03 _____ 710 номерлы карарына кушымта

«Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне-2020» үткәрү сметасы

2020 елның язында РФ Хәрби Көчләренә чакырылырга тиешле гражданнарга бүләкләр сатып алу:

30 данә х 500 сум = 15 000 сум.

БАРЛЫГЫ: 15 000 (унбиш мең) сум.